ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

4 февраль, 2026 ел № 5/10

Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар, аларның гаилә әгъзалары тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләрне шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына рәсми бастыруга бирү Тәртибен раслау турында» 2016 елның 7 апрелендәге 7/17 номерлы Карарын көчен югалткан дип тану хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Көчен югалткан дип танырга:

1) Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар, аларның гаилә әгъзалары тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләрне шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына рәсми бастыруга бирү Тәртибен раслау турында» 2016 елның 7 апрелендәге 7/17 номерлы Карарын, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru 2016 елның 7 апрелендә, «Челнинские известия» газетасының 2016 елның 11 маендагы 33 санында, «Шәһри Чаллы» газетасының 2016 елның 29 апрелендәге 31 санында бастырылган;

2) Шәһәр Советының «Коррупциягә каршы тору буенча Шәһәр Советының аерым Карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 21 февралендәге 23/12 номерлы Карарының 1 өлешен, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru 2018 елның 15 мартында,

«Челнинские известия» газетасының 2018 елның 16 мартындагы 18 санында, «Шәһри Чаллы» газетасының 2018 елның 16 мартындагы 18 санында бастырылган;

3) Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар, аларның гаилә әгъзалары тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләрне шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына рәсми бастыруга бирү Тәртибен раслау турында» 2016 елның 7 апрелендәге 7/17 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 18 мартындагы 6/6 номерлы Карарын, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru 2021 елның 26 мартында, «Челнинские известия» газетасының 2021 елның 24 мартындагы 20 санында, «Шәһри Чаллы» газетасының 2021 елның 26 мартындагы 21 санында бастырылган;

2. Әлеге Карар 2026 елның 1 гыйнварыннан соң барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләре өчен гамәлдә

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев